


**Нурлат муниципаль районы Бикүле төп гомуми белем мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Галиева**

# Лексика буенча өлкән сыйныфларда дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерлек эшләре

# Мастер – класснын максаты

1. Татар теле дәресләрендә дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерлек эшләре; авыр темаларны өйрәнүне җиңеләйтү;
2. Хәтерне, игътибарны, логик фикерләү сәләтләрен үстерү;
3. Кызыклы биремнәр аша туган илгә мәхәббәт тәрбияләү.

# А5 биреме
# Синонимнар рәтен билгеләгез

- Укучы нәрсә белергә тиеш?
- Синонимнар - мәгънәләре ягыннан тәңгәл килгән яки якын торган сүзләр.
- Синонимик оя – бер үк яки якын мәгънәле сүзләр төркеме.
- Доминанта сүз - синонимик оядагы сүзләрне берләштерүче, гомуми төшенчә белдерә һәм телдә продуктив кулланыла торган, стилистик бизәкләрдән азат сүз.


# А-5
# Бирелгән сүзнең антонимын билгеләргә

- Укучы нәрсә белергә тиеш?
- Антонимнар-капма -каршы мәгънәле сүзләр.
- Оксюмороннар-үзара бәйләнешкә керә алмастай антонимнар,сөйләмне җанландыра торган махсус сурәтләү чаралары(бай хәерче,акыллы җүләр, надан галим,сакаллы сабый)

# Бер итеп күрсә дә күзләр,бу-төрле сүзләр

| **Саф омонимнар (төрле грамматик формаларны алганда да аваздаш булып калалар)** | **Омоформалар билгеле бер грамматик формада гына омонимлаша)** | **Омографлар (язылышлары бертөрле булса да, әйтелешләрендә аерма бар)** | **Омофоннар (язылышлары төрле,ә әйтелешләре бертөрле)** |
|---|---|---|---|
| Туп(уенчык)<br>Туп(ату коралы) | Яз(исем)<br>Яз(боерык фигыль) | Бүлмә(исем)<br>Бүлмә(б.фигыль) | Казан-казан |

# Кроссворд чишәбез



- Тест биремнәре
- **А-1. Синонимнар рәтен билгеләгез**
- **1.**суык,салкын
- 2.суык,җылы
- 3.суык,дымлы
- 4.суык,кыш
- **А-2.Бирелгән җөмләдә калын хәрефләр белән күрсәтелгән сүзнең синонимын билгеләгез.**
- *Күләгелерәк урынны сайлап,җиргә ашъяулык җәеп,табын **әзерләделәр***
- 1.кордылар
- 2.яптылар
- 3.җыйдылар
- 4.куйдылар
- **А-3 Җөмләдә калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең антонимын билгеләгез.**
- *Башында яхшы эшләпә,бер-кулында-шырпы,икенче кулында-күкрәгенә кысылган хәлдә картина,**искиткеч** картина*
- *1.ямьсез*
- *2.коточкыч*
- *3.гүзәл*
- *4.матур*
- ***А-4.җөмләдә калын хәрефләр белән күрсәтелгән сүзнең синонимын табыгыз.***
- *Урам як коймага терәлеп дигәндәй үсен утырган **мәһабәт** имәндә аларны син ясаган оя көтә.*
- *1.зур*
- *2.күркәм*
- *3.өлкән*
- *4.эре*
- ***А-5 Надан сүзенең антонимын билгеләгез***
- *1.белемле*
- *2.уңган*
- *3.акылсыз*
- *Белемсез*
- ***А-6 Синонимнар рәтен билгеләгез***
- *1. Зиннәтле,кыйммәтле*
- *2.зиннәтле,әһәмиятле*
- *3.Зиннәтле,матур*
- *4. зиннәтле,очсыз*
- ***А-7Җөмләдә калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең синонимын күрсәтегез.***
- *Нефть кудыра торган насослар тирәсеннән дә әллә ничә **кат** урадылар.*
- *1.тапкыр*
- *2.юл*
- *3.Әйләнә*
- *4.этаж*

- *В-1.Бирелгән җөмләдәге кайсы сүзне **зәмһәрир синонимы** белән алыштырып була?*
- ***Һәм шуны чатнама суыкта бирәү рәхимсез рәвештә бозлы киндер белән усын.***
- ________________________________
- 
- ***В-2** Сөйләмнең сәнгатьлелегенә ирешү өчен,түбәндәге җөмләдәге **тыңлый** синонимын кайсы тотырыклы сүзтезмә белән алыштырганнар?*
- ***Сөйләшеп утыруларына колак сала торгач,сүзләреннән әзме күпме шушы аңлашылды.***
- 
- ***В-3** Сөйләмнең сәнгатьлелегенә ирешү өчентүбәндәге абзацта **дошманнар** сүзенә синоним була алырлык нинди берәмлек кулланылган?*
- ***Юлбасарлар кулына эләккән шәһәрдә кеше бик аз калды.Халык кичә үк, дошман ыргыткан бомболардан өйләргә ут капкач ук,ашыгыч рәвештә шәһәрдән чыгып китте***
- ______________________
- ***В-4.**Түбәндәге җөмләдә кайсы сүзне **укытучы** синонимы белән алыштырып була?*
- ***Беренче тапкыр мәктәпкә килгәч, мөгаллим безне салам җәйгән идәнгә утыртты,һәркайсыбызга берәр дәфтәр,каләм 1әм кара такта бирде.***
- ___________________________
- ***В-**5Түбәндәге җөмләдәге кайсы сүзне **олылаганнар** синонимы белән алыштырып була?*
- ***Авызына күсе капкан мәчене күргән шәһәр кешеләре аны баш киемнәрен салып зурлаганнар.***
- ____________________________
- 
- 
- 

# Тест буенча җаваплар.

- А1-А7 буенча җаваплар барысы да 1
- В-1 ЧАТНАМА СУЫК
- В-2 КОЛАК САЛА
- В-3 ЮЛБАСАРЛАР
- В-4 МӨГАЛЛИМ
- В-5 ЗУРЛАГАННАР